**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2025 елның 1 октябре 405 /исх. номер

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» (Серебрячиха) территориясен планлаштыру проектын карау турында гавами тыңлаулар башлану хакында хәбәр итү**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 февралендәге 96-РС номерлы үзгәрешләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 13.12.2018нче елның 13 нче декабрендәге 117 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» (Серебрячиха) территориясен планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында» 2025 елның 29 сентябрендәге 7 номерлы карары нигезендә, капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга үтәү максатларында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башкарма комитетына хәбәр итә**:**

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» (Серебрячиха) территориясен планлаштыру поектын карау турында 2025елның 1 октябреннән 2025елның 10 октябренә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү турында:

2. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре территориясендә даими яшәүче, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар дип таныла.

3. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» территориясен планлаштыру поектын карау экспозициясе Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969. htm веб-адресы буенча **«Гавами фикер алышу»** бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Лаеш шәһ., Коммунальная ур., 3 й., адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында киңәшмәләр залында узачак. Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре рәсми сайтында https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm веб адресы буенча урнаштырылган проект материаллары экспозициянең бөтен срогы дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында проект белән 2025елның 13 октябреннән 2025елның 14 октябренә кадәр 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин.

.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышы уздырылачак:

- Иске Пристань авылында 2025елның 10 октябрендә 11:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Иске Пристань авылында, 1А Производство урамында спорт залы бинасы (ДЮСШ);

- Лаеш шәһәрендә - 2025елның 10 октябрендә 13:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Лаеш шәһәре, Коммуналь ур., 3 йорт - Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасы;

5. 3 пунктта күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» территориясен планлаштыру документларына акагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне түбәндәге тәртиптә кертергә хокуклы:

- Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Коммунальная ур., 3 адресы буенча гавами тыңлауларны оештыручыга язма рәвештә;

- Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Коммунальная ур., 3 адресы буенча проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язып кую юлы белән.

Шулай ук «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә «Көнчыгыш Лаеш» территориясен планлаштыру документларына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү барышында язмача яисә телдән бирелергә мөмкин.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып. Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокук ияләре булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, биналар турында белешмәләр, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга аларның хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Ачык тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз ризалыкларын бирәләр.

Әлеге карарны "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo. tatarstan.ru/ веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

**Лаеш шәһәре башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **В.А. Арефьев**